ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

22 гыйнвар 2025 ел №160

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге Советының
2024 елның 5 июнендәге 135 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы " Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2024 елның 5 июнендәге 135 номерлы “Җир салымы турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның 2 абзацында "әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса"сүзләрен өстәргә.

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Элек исәпләнгән салым суммасын яңадан исәпләү нәтиҗәләре буенча исәпләп чыгарылган салым салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан өченче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча, шушы яңадан исәпләүгә бәйле рәвештә салым хәбәрнамәсе төзелгән айдан соң килүче айда түләнергә тиеш.";

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru "Норматив документлар" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының финанс - бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов